**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1437**
**18.03.2022**

Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында даими муниципаль маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында шәһәр бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 27 декабрендәге 8471 номерлы карары белән расланган автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында даими муниципаль маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында шәһәр бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктта «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары» сүзләреннән соң «, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус инфекциясе таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 елның 19 мартындагы 208 номерлы карары» сүзләрен өстәргә;

2) 3 пунктта:

- «алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында» сүзләрен төшереп калдырырга;

- «җир өсте электр транспортында» сүзләреннән соң «яңа коронавирус инфекциясе таралуны булдырмау максатларында чикләү чаралары кертүгә бәйле» сүзләрен өстәргә;

3) 10 пунктның 6 пунктчасында «субсидия бирү планлаштырыла торган сүзләрен» төшереп калдырырга;

4) Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында даими муниципаль маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында шәһәр бюджетыннан субсидия бирү өчен юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне сайлап алуны үткәрү турында белдерүнең унтугызынчы абзацында «30» цифрын «15» цифрына алмаштырырга;

5) Автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында даими муниципаль маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле алынып бетмәгән керемнәрне кайтару максатында тәкъдимнәр соратып алуда катнашуга заявканың 3 пунктындагы 5 пунктчасында «30» цифрын «15» цифрына алмаштырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы И.Н. Гайнуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов